ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.11.2022 Казан ш. №564-143/кс-2022

«Кыят торак-коммуналь хуҗалыгы күп тармаклы җитештерү предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте өчен 2023 елга эчәргә яраклы суга тариф билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 17 ноябрендәге 38-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасына туры китереп, салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Кыят торак-коммуналь хуҗалыгы күп тармаклы җитештерү предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте (алга таба – «Кыят торак-коммуналь хуҗалыгы күп тармаклы җитештерү предприятиесе» ҖЧҖ) өчен эчә торган суга тариф билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тариф 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелә.

3. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Кыят торак-коммуналь хуҗалыгы күп тармаклы җитештерү предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартларына туры китереп, иректе файдаланылырга

тиешле мәгълүматны чираттагы җайга салу чорына тариф билгеләү турындагы карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән соңга калмыйча ачарга.

4. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының ««Кыят торак-коммуналь хуҗалыгы күп тармаклы җитештерү предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте өчен 2022 елга эчәргә яраклы суга тариф билгеләү хакында» 17.11.2021 №283-40/кс-2021 карарын 2022 елның 1 декабреннән үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карар 2022 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач гамәлгә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
17.11.2022 №564-143/кс-2022
карарына кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Кыят ТКХ КҖП» ААҖ өчен
эчәргә яраклы суга 2023 елга тариф

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|
| | Буа муниципаль районы | |
| 1 | «Кыят торак-коммуналь хуҗалыгы күп тармаклы җитештерү предприятиесе» ААҖ* | 41,86 |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге